**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О регулировании отдельных вопросов в сфере добровольчества (волонтерства) и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 июня 2018 года

## Статья 1. Предмет регулирования настоящего Закона

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 11 августа 1995 года № 135-ФЗ «О благотворительной деятельности и добровольчестве (волонтерстве)» и иными федеральными законами регулирует отдельные вопросы в сфере добровольчества (волонтерства).

## Статья 2. Основные понятия

Основные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, что и в Федеральном законе от 11 августа 1995 года № 135-ФЗ «О благотворительной деятельности и добровольчестве (волонтерстве)».

## Статья 3. Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства)

1. Органы государственной власти Республики Татарстан осуществляют полномочия в сфере добровольчества (волонтерства) в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства) относятся:

1) законодательное регулирование в сфере добровольчества (волонтерства);

2) контроль за исполнением законодательства Республики Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства);

3) иные полномочия, предусмотренные федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям Президента Республики Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства) относится утверждение порядка взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями.

4. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства) относятся:

1) оказание поддержки организаторам добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческим (волонтерским) организациям, в том числе в их взаимодействии с государственными и муниципальными учреждениями и иными организациями, социально ориентированным некоммерческим организациям, государственным и муниципальным учреждениям, обеспечивающим оказание организационной, информационной, методической и иной поддержки добровольцам (волонтерам), организаторам добровольческой (волонтерской) деятельности и добровольческим (волонтерским) организациям;

2) поддержка муниципальных программ (подпрограмм), содержащих мероприятия, направленные на поддержку добровольчества (волонтерства);

3) иные полномочия, предусмотренные федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

5. К полномочиям органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства) относятся:

1) участие в реализации государственной политики в сфере добровольчества (волонтерства);

2) разработка и реализация государственных программ (подпрограмм) Республики Татарстан, содержащих мероприятия, направленные на поддержку добровольчества (волонтерства), с учетом национальных и региональных социально-экономических, экологических, культурных и других особенностей;

3) популяризация добровольческой (волонтерской) деятельности;

4) методическое обеспечение органов местного самоуправления в Республике Татарстан и содействие им в разработке и реализации мер по развитию добровольчества (волонтерства) на территориях муниципальных образований;

5) формирование координационных и совещательных органов в сфере добровольчества (волонтерства), создаваемых при органах исполнительной власти Республики Татарстан;

6) иные полномочия, предусмотренные федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

Статья 4. **Полномочия органов местного самоуправления в Республике Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства)**

К полномочиям органов местного самоуправления в Республике Татарстан в сфере добровольчества (волонтерства) относятся:

1) формирование и осуществление муниципальных программ (подпрограмм), содержащих мероприятия, направленные на поддержку добровольчества

(волонтерства), с учетом национальных и местных социально-экономических, экологических, культурных и других особенностей;

2) утверждение порядка взаимодействия органов местного самоуправления, муниципальных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями;

3) оказание поддержки организаторам добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческим (волонтерским) организациям, в том числе в их взаимодействии с муниципальными учреждениями и иными организациями, социально ориентированным некоммерческим организациям, государственным и муниципальным учреждениям, обеспечивающим оказание организационной, информационной, методической и иной поддержки добровольцам (волонтерам), организаторам добровольческой (волонтерской) деятельности и добровольческим (волонтерским) организациям.

Статья 5. **О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О молодежи и государственной молодежной политике в Республике Татарстан»**

Внести в Закон Республики Татарстан от 19 октября 1993 года № 1983-XII «О молодежи и государственной молодежной политике в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 26 мая 2005 года № 73-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1993, № 10; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I часть); 2013, № 4 (I часть); 2014, № 1 – 2; 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I) следующие изменения:

1) абзац пятый статьи 2 после слова «добровольческой» дополнить словом «(волонтерской)»;

2) абзац тринадцатый статьи 5 после слова «добровольчества» дополнить словом «(волонтерства)»;

3) абзац второй статьи 10 после слова «добровольческой» дополнить словом «(волонтерской)».

Статья 6. **О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О свободе совести и о религиозных объединениях»**

Внести в статью 22 Закона Республики Татарстан от 14 июля 1999 года № 2279 «О свободе совести и о религиозных объединениях» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1999, № 8 (II часть); 2001, № 12; 2004, № 2 (I часть); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I часть); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I) изменения, дополнив ее пунктами 3 – 4 следующего содержания:

«3. Религиозные организации в соответствии со своими внутренними установлениями вправе привлекать добровольцев (волонтеров) для участия в организации богослужений, других религиозных обрядов и церемоний, а также для выполнения работ, оказания услуг, направленных на поддержку и обеспечение видов деятельности религиозных организаций, предусмотренных их уставами.

4. Религиозные организации вправе заключать в соответствии с Федеральным законом от 26 сентября 1997 года № 125-ФЗ «О свободе совести и о религиозных объединениях» с добровольцами (волонтерами) гражданско-правовые договоры о добровольческой (волонтерской) деятельности.».

Статья 7. **О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «О физической культуре и спорте»**

Внести в часть $1^1$ статьи 12 Закона Республики Татарстан от 8 октября 2008 года № 99-ЗРТ «О физической культуре и спорте» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 10 (I часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2013, № 6 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II часть); 2015, № 3, № 7 (I часть), № 10 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I); 2018, № 29 (часть I) изменение, заменив слово «волонтерам» словами «добровольцам (волонтерам)».

Статья 8. **О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О профилактике наркомании и токсикомании»**

Внести в Закон Республики Татарстан от 29 октября 2009 года № 50-ЗРТ «О профилактике наркомании и токсикомании» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11; 2014, № 7; 2016, № 5) следующие изменения:

1) в статье 6:

а) в наименовании слова «, спорта и туризма» заменить словами «и спорта»;

б) в абзаце первом части 1 слова «, спорта и туризма» заменить словами «и спорта»;

в) в пункте 3 части 1 слово «волонтерского» заменить словами «добровольческого (волонтерского)»;

г) в абзаце первом части 2 слова «, спорту и туризму» заменить словами «и спорту»;

2) в части 1 статьи 22 слова «, спорту и туризму» заменить словами «и спорту».

Статья 9. **О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в сфере социального обслуживания граждан в Республике Татарстан»**

Пункт 13 статьи 4 Закона Республики Татарстан от 18 декабря 2014 года № 126-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере социального обслуживания граждан в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I) после слова «добровольцев» дополнить словом «(волонтеров)».

Статья 10. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
30 июня 2018 года
№ 48-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон "Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында" 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

## 2 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр "Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында" 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

## 3 статья. **Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләрне федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсен законнар белән җайга салу;

2) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

3. Татарстан Республикасы Президентының ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләренә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, аларның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшләве тәртибен раслау керә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмаларына, шул исәптән аларның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, башка оешмалар белән үзара эшләвендә ярдәм күрсәтү, ихтыярый ярдәм итүчеләргә (волонтерларга), ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмаларына оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә булышлык итү;

2) ихтыярыйлыкка (волонтерлыкка) ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралары булган муниципаль программаларга (ярдәмче программаларга) булышлык итү;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) милли һәм региональ социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, ихтыярыйлыкка (волонтерлыкка) ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралары булган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) эшләү һәм гамәлгә ашыру;

3) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген популярлаштыру;

4) Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын методик яктан тәэмин итү һәм аларга муниципаль берәмлекләр территорияләрендә ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда ярдәм итү;

5) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары каршында төзелә торган ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге координацион һәм киңәшмә органнарын булдыру;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

## 4 статья. **Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) милли һәм җирле социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, ихтыярыйлыкка (волонтерлыкка) ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралары булган муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) булдыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшләве тәртибен раслау;

3) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмаларына, шул исәптән аларның муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар белән үзара эшләвендә ярдәм күрсәтү, ихтыярый ярдәм итүчеләргә (волонтерларга), ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга һәм ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмаларына оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә булышлык итү.

5 статья. **"Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

"Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 1 – 2; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның бишенче абзацында "ихтыярый эшчәнлекне" сүзләрен "ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген" сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяның унөченче абзацында "ихтыярый эшчәнлекнең" сүзләрен "ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегенең" сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяның икенче абзацында "ихтыярый эшчәнлекнең" сүзләрен "ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегенең" сүзләренә алмаштырырга.

6 статья. **"Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

"Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3;

Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 3 – 4 пунктларны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

“3. Дини оешмалар үзләренең эчке күрсәтмәләре нигезендә гыйбадәт кылуларны, башка дини йолаларны һәм тантаналар үткәрүне оештыруда катнашу, шулай ук дини оешмаларның үз уставларында каралган эшчәнлек төрләренә ярдәм итүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен ихтыярый ярдәм итүчеләрне (волонтерларны) җәлеп итәргә хокуклы.

4. Дини оешмалар “Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтерлар) белән ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеге турында граждани-хокукый шартнамәләр төзергә хокуклы.”.

7 статья. **“Физик культура һәм спорт турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы $1^1$ өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш) “Волонтерларга” сүзен “Ихтыярый ярдәм итүчеләргә (волонтерларга)” сүзләренә алмаштырырга.

8 статья. **“Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

“Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында” 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11; 2014, № 7; 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) исемендә “, спорт һәм туризмны” сүзләрен “һәм спортны” сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең беренче абзацында “, спорт һәм туризмны” сүзләрен “һәм спортны” сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 өлешнең 3 пунктында “волонтерлык” сүзен “ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык)” сүзләренә алмаштырырга;

г) 2 өлешнең беренче абзацында “, спорт һәм туризмны” сүзләрен “һәм спортны” сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяның 1 өлешендә “, спорт һәм туризм” сүзләрен “һәм спорт” сүзләренә алмаштырырга.

**9 статья. “Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

“Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 13 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш) “үз теләге белән эшләүчеләргә” сүзләрен “ихтыярый ярдәм итүчеләргә (волонтерларга)” сүзләренә алмаштырырга.

**10 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 июнь
№ 48-ТРЗ